ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

5 май, 2023 ел № 23/9

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге 43/9, 2010 елның 26 маендагы 50/8, 2011 елның 15 декабрендәге 15/9, 2012 елның 20 апрелендәге 18/8, 2015 елның 15 апрелендәге 39/11, 2018 елның 21 февралендәге 23/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/11, 2019 елның 23 маендагы 31/7, 2020 елның 18 мартындагы 38/7, 2021 елның 18 мартындагы 6/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 5 пункт 18 пунктчада «(тарихи һәм » сүзләреннән соң «Россия Федерациясе халкының» сүзләрен өстәргә;

2) 49 пунктта «бирелергә мөмкин» сүзләрен «бирелә» сүзенә алыштырырга;

3) 58 пунктта:

- беренче абзацта «тапшырылырга мөмкин» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алыштырырга;

- 2 пунктчада «муниципаль органнарга» сүзләрен төшереп калдырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча өстәргә:

«8) юридик затларга, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре (шул исәптән хөкүмәтара килешүләр), әлеге мөлкәт белән эш итүнең башка тәртибен билгели торган федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты актлары,

Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары, закон көченә кергән суд карарлары нигезендә».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев